**Автор публикации: Шайхутдинова Фаузия Миннулловна, воспитатель МБДОУ Верхнетакерменский детский сад «Шатлык» филиал Деуковский детский сад»Ляйсан» с.Деуково, Мензелинский район, Республика Татарстан**

**Название работ: «Статья»**

**Тема: «Солдат озату йоласы «Чиккән кулъяулыгым-вәгъдә бүләгем»**

# Солдат озату йоласы.

## “Ватанымны саклаучыга, вәгъдә бүләгем - чиккән кулъяулыгым»

Изге хисләр белән чиккән кулъяулыгым,
Сөйгән ярым, сиңа, вәгъдә буләгем,
Исән- сау йореп,сөенеп кайт,
Шушы Сина, Изге теләгем.

Һәр кеше үз халкының үткәнен, гореф-гадәтләрен белергә тиеш. Үткәнне белмәүчеләрнең киләчәге юк, — ди халык. Туйлар үткәрү, исем кушу, аулак өй, кәләшнең килүе, кыз карау, өй туе, солдатны озату… Халык бәйрәмнәре, гореф-гадәтләр — кешегә үз тормыш рәвешенә һәм таләпләренә җайлашырга ярдәм итә торган нәрсә. Яшь буын, кечкенәдән бәйрәмдә катнашу тәртибен өйрәнә. Һәр кеше, әлбәттә, үз-үзен күрсәтә, милли тәрбия ала.

Кичке уеннар элек-электэн халыкнын ин матур, ин куркэм йолаларыннан саналган хэм алар жыен булган коннэн башлап печэнгэ тошкэнче дэвам иткэн. Халыкта хэр нэрсэнен уз тэртибе булган.

Жэйге матур кичлэрдэ, кояш баткач, картлар яткач, су буйлары, урман аланнары, ямь-яшел болыннар яшьлэрнен шат авазларына кумелгэн. Кичке уеннарда жыр-бию, уен-колке бер генэ минутка да тынып тормаган. Анда жырлы- биюле тугэрэк уеннары, ике урам арасында жыр ярышлары, шаян такмаклар эйтешу, кумэк хэм ялгыз биюлэр хэм башка кызыклы уеннар уйналган.

.Йола — ул теге яки бу дини кануннарны үтәү яки борынгы заманнардан бирле яшәп килгән торак-көнкүреш традицияләрен урнаштыру белән бәйле тәртип һәм гореф-гадәтләр. Гасырлардан-гасырларга, буыннан-буынга, әби-бабайлардан әти-әниләргә, ата-аналардан балага үзләренең борынгы бәйрәмнәре, гореф-гадәтләре, күпмедер дәрәҗәдә үзгәргән булса да, безнең көннәргә дә килеп җиткән. Әйе, без бәләкәй чакларда әле халкыбызның милли йолалары,гореф-гадәтләре тормышыбызда киң колач алган иде. Нинди генә матур бәйрәмнәр юк иде. Ул каз өмәсе дисенме, барлык дус- туганнар җыелып,җырлый-җырлый каз чистарталар,ияреп килгән безнең кебек кечкенә балалар мунчада каз канаты сыдыра , аннары ул сыдырылган канатларны, киләсе елга да казлар куп булып чыксын дип тели,тели су буена кадәр чәчеп бара иде.Казның эчен алганны

туземсезлек белән котеп тора идек,чонки каз куыгын алып,юып бирәләр иде лә,аны без шар урынына кабартып уйный идек. Эш бетугә тәмле итеп мичтә каз тәбикмәге пешерелә иде.Ә инде кич белән барлык булышучылар кичке табынга ашка чакырыла иде. Э бу өйдән инде җырлы-моңлы шат авазлар ишетелеп тора иде. Иртә яздан кардан ачылган урыннарда авылның барлык бала-чагасы җыелып торле хәрәкәтле ,җырлы-биюле уеннар уйныйлар иде. Алар тавышыннан яланнар яңгырап тора иде.Ул аулак өйләр,кичке уеннар. Нинди куңеллелек, нинди рәхәтлек бирә иде куңелләргә.Моңлы гармун тавышы, яшьләрнең моңлы сандугачтай гармунга кушылып җырлаулары, йөрәкләрне җилкендерә торган бию көйләре, яшьләрнең шаярып көлүләре...

Хәзерге вакытта онытылып бара торган йолаларның берсе –"Солдат озату"

Армияга китәргә повестька килү яшен тизлегендә бөтен авылга тарала, Яшьләр җыелып гармунга кушылып җырлап, авыл буйлап әйләнәләр. Алар һәр өйгә кереп ,өлкәннәрнең хәер фатихасын алып,саубуллашып йориләр иде. Өлкәннәр солдатның исән-имин хезмәт итеп кайтуларын теләп дога кылып калсалар, яшь кызлар истәлек буләге итеп узләренең чиккән кульяулыкларын буләк итәләр.Егет өчен яулыкларның иң матуры, иң кадерлесе, иң якыны, әлбәттә сөйгән ярныкы, көтәргә вәгъдә биреп буләк ителгәне. Ул кульяулыкларны берсенә-берсен төйнәп беркетеп , солдатка китуче егет муенына асалар , бу инде солдатка китучене башкалардан аерып тора иде. Яшьләрне кичке солдат озату кичәсенә чакыралар. Анда тәмле татар ризыкларыннан мул табын әзерләнә,солдатка китүчегә матур изге теләкләр теләнә,күңелле,сагышлы җыр,моң агыла,куңелле бию көйләре яңгырый.. Кичтән солдат ашы үткәрелсә, иртән иртук авыл капкасында яшьләр армиягә китучене озатырга җыелалар иде. Менә китә инде анда сагышлы матур җырлар ,такмаклар, куңелле биюләр...

1. Солдат ашы май гына,
   Тарелкасы сай гына,
   Кайтырга да куп калмады ,
   24 ай гына.
2. Әнкәй ашың пешәме,
   Пешәме, сүреләме?
   Газиз балаң чыгып китә
   Үзәгең өзеләме?
3. Военкомат ишек алдын
   Себермәсәң дә такыр,
   Безнең яшь егетләребез,
   Себер китсәдә кайтыр.

   4.Военкомат янса иде,
   Камиссарлары белән,
   Армияга китсәң иде,
   Сөйгән ярларың белән

   5. Солдатларга аш бирәләр,
   Калай савытлар белән
   Смирно,дип кычкыралар
   Ачы тавышлар белән .

   6. Әнкәй ашың пешәр чакта,
   Балаларын җыелыр
   ,Алар булып без булмагач,

Күз яшьләрен коелыр.
7.Военкомат алларына
Яшел чирәм үсмәгән,
Яз кайтмасак,
Көз кайтырбыз,
Анда туып үсмәгән.
8. Ишегалды яшел чирәм
Атларга кимертмәгез,
Кулларыгыз яза белә,
Хатларга тилмертмәгез.
9. Без үскәндә , үскән идек,
Тал тамырлары кебек.
Үсеп җиткәч таралыштык,
Кош балалары кебек.
Монда халкыбыз узенең уй кичерешләрен шигырь юлларына салып,такмак итеп җырлаган.

Бүгенге көндә балалар бакчасы тәрбиячеләре алдында торган бурычларның иң мөһиме – сабыйларга максатлы рәвештә - үз туган телен өйрәтү, шулай ук аларны халкыбызның сәнгате, гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, йолалары , милли әдәбияты белән таныштыру.Татар халкының мең елларга сузылган тормыш тәҗрибәсе, уйлары, гадәтләре, кешене шәхси итүче сыйфатлары, аның телендә образлы сөйләмнәрендә, мәкаль-әйтемнәрендә, җыр һәм әкиятләрендә чагылыш тапкан. Баланы беренче көненнән үк туплый башлаган хәзинәсе – туган теле. Ана сөте белән кергән туган тел сабыйда газиз анасына, әтисенә, әби-бабасына, туганнарына, туган туфрагына, чишмә һәм урманнарына, тереклек дөньясына мәхәббәт, аны белергә, төшенергә омтылу хисләре дә тәрбияли. Балаларга ана телен өйрәтүдә төп бурычларның берсе – халкыбызның әдәби байлыгына, фольклор мирасына, аның гореф гадәтләренә таяну. Тел – тормыш чыганагы, белем чишмәсе. Тел ул зур бер гөлбакча кебек анда халык педагогикасына таянып эш итү зарур. Җор телле халкыбыз иҗат иткән табышмаклар, санамышлар, такмаклар, әкиятләр, бәетләр, моңлы бишек җырлары – тел өйрәнүдә иң бай чыганак